**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**"22" сентябрь 2022 ел** **№272**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 25 декабрендәге 301 номерлы «Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар туклandыруны оештыру турында нигезләмә хакында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән туклandыруны оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (19.11.2021 №294, 22.07.2022 № 197 карарлар редакциясендә)

Көч структуралары хезмәткәрләре балаларына түләүсез кайнар туклану бирү турында җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгать итүгә бәйле рәвештә, карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 25 декабрендәге 301 номерлы «Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар туклandыруны оештыру турында нигезләмә хакында» карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән туклandыруны оештыру турында нигезләмәгә (19.11.2021 №294, 22.07.2022 № 197 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5.1 пунктының алтынчы абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясенең Азнакай районы буенча эчке эшләр бүлекчәсе территориаль бүлекчәсе һәм «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Азнакай районы буенча бүлекчәсе хезмәткәрләре балалары.»;

1.2. 5.2. пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Социаль ярдәмгә мохтаҗ аерым категория укучыларга түләүсез кайнар туклану бирү өчен документлар исемлеге:

а) күпбалалы аз керемле гаиләләр өчен:

- исемлек буенча документларга кушып, ата-ананың (законлы вәкилнең) берәрсенең язма гаризасы;

- барлык балаларга (эшләмәүчеләргә һәм гаиләдә яшәүчеләргә) туу турында таныклык күчермәләрен;

- әгәр гаиләдә балаларның берсе студент булса, көндезге бүлектү укуны раслаучы уку йортыннан белешмә;

- бушлай кайнар туклану бирүдә өстәмә социаль ярдәм күрсәтелүгә мохтаҗ укучыны исемлеккә кертү турында комиссия карары;

- Азнакай муниципаль районы матди ярдәм үзәгенең 3 нче филиалы «Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ һәм Азнакай муниципаль районының Республика матди ярдәм үзәгенең 3 нче филиалы арасында социаль ярдәм чаралары алучылар турында мәгълүмат (әлеге нигезләмәнең 5.3 пункты нигезендә).

б) авыр тормыш хәлендә калган гаиләләрдәге балалар өчен:

- сыйныф җитәкчесенең язма гаризасы (үтенече);

- авыр тормыш хәлендә калган укучылар гаиләсенең торак-көнкүреш шартларын тикшерү акты;

- бушлай кайнар туклану бирүдә өстәмә социаль ярдәм күрсәтелүгә мохтаҗ укучыны кертү турында комиссия карары.

в) сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар статусына ия инвалид балалар өчен:

- психолог-медицина-педагогик комиссия бәяләмәсе.

г) Азнакай муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениесенең махсуслаштырылган спорт сыйныфы укучылары өчен:

- баланы махсуслаштырылган спорт сыйныфына кертү турында ата-ананың (законлы вәкилнең) берсенең язма гаризасы.

д) Россия Эчке эшләр министрлыгының Азнакай районы буенча территориаль бүлекчәсе хезмәткәрләренең балалары өчен яки "Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе (Татарстан):

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Азнакай районы буенча территориаль бүлекчәсе хезмәткәре яисә Азнакай районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәре - “Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча ведомстводан тыш саклау идарәсе” ФДБУ филиалы - ата-аналарның берсенең (законлы вәкиленең) эш урыныннан белешмә.»;

2. Әлеге карарның 1.1 пунктының икенче абзацы 2022 елның 01 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов